Республика Татарстан

Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

06.05.2020

Менделеевск ш.

№ 282

«2019 - 2021 елларга Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
физик культураны һәм спортны үстерү»
район максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында

«2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» район максатчан программасының программа чаралары исемлегенә үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 14 декабрендәге 838 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» район максатчан программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның «программа чаралары исемлеге» VI бүлегенең 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 3.3, 3.4, 3.5 пунктчалары белән тулыландырырга:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.3 | Яшь белгечләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар | Спорт мәктәпләре | 2019-2021 | ТР бюджеты | 34,7 | | |
| 3.4 | Тренерларга һәм спортчы инструкторларга югары нәтиҗәләр өчен ярдәм итүгә | Спорт мәктәпләре | 2019-2021 | ТР бюджеты | 26,1<br>324,46 | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | юнәлдерелгән чаралар | | | | | | |
| 3.5 | Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль спорт мәктәпләренең спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыруга һәм хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында (яисә) хоккей буенча Россия Федерациясе чемпионатында (А подтөркеме) катнашу өчен Менделеевск муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү | «Айсберг» спорт мәктәбе муниципаль бюджет учреждениесе | 2019-2020 | ТР бюджеты | | 392,4 | |

1.2. Программаның VI бүлегенең 5 пунктындагы 5.1 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.1 | Спорт җиһазлары, инвентарь һәм спорт мәктәпләре экипировкасын сатып алу | Спорт мәктәпләре | 2019-2021 | ТР бюджеты | 211,29 | 208,35 | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының mendeleevsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контольдә тотуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.И. Ямалееваga йөкләргә.

Җитәкче А.Р. Абдуллин